ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

10.07.2019 Олы Кайбыч авылы № 311

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль
районы Башкарма комитетының 2019елның
29 маенда чыккан 257 номерлы «Кайбыч
муниципаль районы авыл җирлекләре җирле
үзидарә органнары тарафыннан күрсәтелә торган
муниципаль хезмәт күрсәтү административ
регламентларын раслау турында» карарына
үзгәрешләр кертү турында

РФ Хөкүмәтенең 19.11.2014 чыккан 1221номерлы «Адреслар бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару Кагыйдәләрен раслау турында» Карары, Россия Минюстының 06.06.2017 чыккан 97номерлы «Җирлекләрнең администрация башлыклары һәм җирлек җирле үзидарәләренең махсус вәкаләтле вазыйфаи затлары, муниципаль районнар җирле администрация башлыклары һәм муниципаль районнар җирле үзидарәләренең махсус вәкаләтле затлары тарафыннан нотариаль гамәлләр кылу тәртибе турында Инструкцияне раслау турында» Приказы нигезендә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР КЫЛА:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының 2019елның 29 маенда чыккан 257 номерлы «Кайбыч муниципаль районы авыл җирлекләре җирле үзидарә органнары тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәт күрсәтү административ регламентларын раслау турында» карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1. 2 кушымтаның 1.5 пункты 10 абзацын яңа редакциядә бәян итәргә:

«планлаштыручы структура элементы» - зона (массив), район (шул исәптән торак район, микрорайон, квартал, сәнәгать районы), гражданнар тарафыннан үз мәнфәгатьләрендә бакчачылык алып бару территориясе»;

3 кушымтаның 2.5. пункты 2подпунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«2. Күчермәләрнең яки алардан өземтәләрнең дөреслеген раслаучы документлардагы битләр саны бердән артык булганда, алар бөтенлегендә шик тумаслык ысул белән тиешенчә беркетелгән булырга тиеш.

Документ бирелгән максатлар өчен андагы төзүтә һәм кимчелекләр мөһим булмаса, җирле үзидарә вазыйфаи заты күчермәләрнең дөреслеген раслау өчен мондый документны алырга хокуклы»;

3 кушымтаның 2.5. пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| 2.9. Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату яки кире кагу өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Хезмәт күрсәтүне туктату өчен нигез каралмаган.<br>Баш тарту өчен нигез:<br>1) Әлеге гамәлне кылу Россия Федерациясе канунчылыгына каршы килә;<br>2) Гамәл икенче җирлек яки муниципаль район җирле үзидарә вазыйфаи заты тарафыннан (варислык буенча күчкән милекне саклау һәм аның белән идарә итү очракларында) яки нотариус тарафыннан башкарылырга тиеш;<br>3) нотариаль гамәл башкару турында сорап эшкә яраксыз гражданин яисә тиешле вәкаләтләргә ия булмаган вәкил, җирлектә яшәү урыны яки вакытлыча булу урыны буенча теркәлүе булмаган гражданин мөрәҗәгать иткән;<br>4) юридик зат исеменнән башкарыла торган килешү аның, уставы яки нигезләмәсендә күрсәтелгән максатларга каршы килә;<br>5) килешү Россия Федерациясе канунчылыгы таләпләренә туры килми;<br>6) нотариаль гамәл башкару өчен тапшырылган документлар Россия Федерациясе канунчылыгы таләпләренә туры килми;<br>7) нотариаль гамәл башкару өчен тапшырылган документларда бәян ителгән фактлар раслау Россия Федерациясе канунчылыгы нигезендә таләп ителсә, Россия Федерациясе канунчылыгы белән билгеләнгән тәртиптә расланмаган | |

2 кушымтаның 2.10. пункты 8 абзацын яңа редакциядә бәян итәргә:

«җирле үзидарә вазыйфаи затлары тарафыннан нотариаль гамәлләр башкарылганда Россия Федерациясе Салым кодексының 333.35 статьясы 1пунктының 11,12 подпунктлары, 333.38 статьясы нигезендә физик һәм юридик затларга дәүләт пошлинасы түләүгә ташламалар ясала»

4 кушымтаның 2.9. пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| 2.9. Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату яки кире кагу өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Хезмәт күрсәтүне туктату өчен нигез каралмаган.<br>Баш тарту өчен нигез:<br>1) Әлеге гамәлне кылу Россия Федерациясе канунчылыгына каршы килә;<br>2) Гамәл икенче җирлек яки муниципаль | |

| | | |
|---|---|---|
| | район җирле үзидарә вазыйфаи заты тарафыннан (варислык буенча күчкән милекне саклау һәм аның белән идарә итү очракларында) яки нотариус тарафыннан башкарылырга тиеш;<br>3) нотариаль гамәл башкару турында сорап эшкә яраксыз гражданин яисә тиешле вәкаләтләргә ия булмаган вәкил, җирлектә яшәү урыны яки вакытлыча булу урыны буеча теркәлүе булмаган гражданин мөрәҗәгать иткән;<br>4) юридик зат исеменнән башкарыла торган килешү аның, уставы яки нигезләмәсендә күрсәтелгән максатларга каршы килә;<br>5) килешү Россия Федерациясе канунчылыгы таләпләренә туры килми;<br>6) нотариаль гамәл башкару өчен тапшырылган документлар Россия Федерациясе канунчылыгы таләпләренә туры килми;<br>7) нотариаль гамәл башкару өчен тапшырылган документларда бәян ителгән фактлар раслау Россия Федерациясе канунчылыгы нигезендә таләп ителсә, Россия Федерациясе канунчылыгы белән билгеләнгән тәртиптә расланмаган. | |

2. Әлеге карарны хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырырга һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Башкарма комитет Җитәкчесенең төзелеш һәм ТКХ буенча урынбасары Ф.Ш.Әхмәтовка йөкләргә.

Җитәкче А.Н.Макаров